УДК 801.8

*Ә.Т. Сибгатуллина*

# ТАТАР ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ӘНКАРАДАГЫ МИРАСЫ ИГЪТИБАР СОРЫЙ

В Анкаре существует Институт исследования тюркских культур (ТКАЕ), учрежденный в 1961 году тремя видными учеными. Один из них татарский ученый профессор Ахмет Тимер (1913–2003) возглавлял институт с 1962 по 1975 годы, казанские и крымские татары входили в учредительный совет Института, финансовую помощь оказывал видный татарский благотворитель Ахмет Вели Менгер (1891–1978). Институт занимался изучением языка, литературы, истории, искусства тюркоязычных народов мира, выпускал журналы по этому профилю, проводил научные конференции и симпозиумы, готовил и издавал научные труды и сборники статей, посвященные известным тюркологам. Здесь были опубликованы книги многих видных татарских ученых, а также факсимильное издание книги Ш. Марджани, переводы на турецком языке прозведений Г. Тукая. В хранилище Института находится наследие татарских ученых, проживших в Анкаре большую часть жизни и завещавших свои библиотеки и архивы ТКАЕ. К сожалению, это наследие из-за финансовых проблем многие годы лежит в неописанном виде и хранится в коробках и мешках на третьем этаже неотапливаемого здания института.

**Ключевые слова:** татарские ученые за рубежом, Институт изучения тюркских культур, Ахмет Тимер, татароведение.

Ankara hosts the Institute for the Study of Turkic Cultures (TKAE), established in 1961 by three prominent scientists. One of them, Tatar Professor Akhmet Timer (1913–2003), headed the Institute from 1962 to 1975. Many Kazan and Crimean Tatars were members of the founding council, whereas financial assistance was provided by a prominent Tatar benefactor, Akhmet Veli Menger (1891–1978). The Institute engaged in the study of languages, works of literature, history and art by the Turkic-speaking peoples of the world; the Institute also published scientific journals, organised scientific conferences and symposia, as well as prepared and published scientific works and collections of articles dedicated to famous Turkologists. In particular, the Institute published books of many prominent Tatar scientists, as well as a facsimile edition of Sh. Mardzhani's book and translations of G. Tukay's works into Turkish. Today the repository of the Institute contains the heritage of Tatar scientists who lived in Ankara most of their lives and who bequeathed their libraries and archives to the TKAE. Unfortunately due to financial problems of the Institute this legacy has not been studied for many years; archival materials are currently stored in boxes and bags on the third floor of the unheated building of the Institute which poses a serious risk to the preservation of the documents.

**Keywords:** Tatar scientists abroad, Institute for the Study of Turkic Cultures, Akhmet Timer, Tatar studies.

Төркиянең башкаласы Әнкарада Төрек тарих курумы, Төрек тел курумы, Әнкара университеты тел, әдәбият, тарих һәм география факультеты кебек рәсми оешмалар Казан татар галимнәре белән

бәйләнешле истәлекләрне саклый, шәһәрнең Каршыйака муниципалитетына караган зиратта гына да никадәр мөһаҗир татар зыялысы күмелгән: монда Уганнар, Акышлар, Кошайлар, Дәүләтшаһлар, Өзәрләр, Одарлар һ.б. гаиләләрнең каберлекләре бар. Бүгенге көндә башкалада яшәгән татарлар, Г. Тукай урамында урнашкан Казан культура һәм ярдәмләшү дәрнәге (җитәкчесе Фуат Тениш) бу каберлекләрне чистартып-карап тора. Шактый актив иҗтимагый тормыш алып баручы дәрнәк әһелләренең дә бик белеп бетермәгән (бәлки дә белеп тә, ишеген ачтырып керә алмаган) татар мирасы тупланган тагын бер гаҗәеп оешма бар Әнкарада, ул Төрки культураны өйрәнү институты исемен йөртә, төрекчәсе: Türk Kültürünü Araştırma Enstitüsü (ТКАЕ – алга таба шулай биреләчәк). Бу оешмага нигез салучы һәм дистәләрчә еллар анда эшчәнлек алып баручылар арасында безнең якташларыбыз, күренекле тюрколог галимнәребез булган һәм күбесенең китапханәсе яки архивы да шушы институтта саклана, тик, ни кызганыч, әлегә кадәр ул мирас тәртипкә китерелмичә, өйрәнелмичә төргәкләрдә, капчыкларда ята бирә. Татарстандагы рәсми һәм иҗтимагый оешмаларның әлеге мәсьәләгә игътибарын җәлеп итү максатында, бу язмада кыскача ТКАЕның тарихы, эшчәнлеге һәм хәзерге халәте турында мәгълүмат[1] бирүне кирәк таптым.

Институт 1961 елда өч зур галимнең инициативасы белән җәмгыять файдасына гыйльми хезмәтләр башкару максатында төзелә: мөдир булып азәрбәйҗан профессоры Абидин Итил (1910–1980), мөдир ярдәмчесе итеп профессор Осман Нәдим Туна (1923–2001), генераль секретарь итеп Казан татары профессор Әхмәт Тимер (1913–2003) билгеләнә. Бу өч шәхеснең тырышлыгы белән фәнни-эзләнү институты ачарга дәүләттән рөхсәт алына һәм 1961 елның 1 ноябрендә чыккан карар нигезендә ТКАЕ рәсми рәвештә теркәлә. Оешма төрки халыкларның теле, әдәбияты, тарихы, этнографиясе, сәнгате белән бәйле булган эзләнүләр алып бару, гыйльми хезмәтләр бастыру, конференцияләр оештыру белән шөгыльләнергә, ул вакытта әле бер хыял гына булган СССР да яшәгән төрки халыклар вәкилләре белән фәнни багланышлар булдырырга планлаштыра. Институтның шигаре исә Мостафа Кәмал Ататөреккнең «Тормышта иң ышанычлы ориентир – фән», дигән сүзләре була.

1962 елда ТКАЕ оештыручыларыннан санскрит белгече Абидин Итил белән шумеролог Осман Н. Туна, башка җиргә күчү сәбәпле (мәсәлән, О.Н. Туна Америкага эшкә/укырга китә), институт җитәкчелегеннән аерылалар, мөдир булып Әхмәт Тимер кала һәм 1974 елның ахырына кадәр әлеге вазифаны башкара. Бу еллар институтның иң уңышлы эшләгән чоры дип әйтергә була. ТКАЕ әгъзалары арасында Казан татарлары, башкортлар, Кырым татарлары арасыннан чыккан галимнәр дә мөһим роль уйный: башкорт Габделкадыйр Инан (1889–1976), кырым татарларыннан Хәниф Алтан (1905–1963), Хәлил Иналҗык (1916–2016), Кәмал Ортайлы (1909–1963), татарлардан

[1] Бу мәгълүматның күпчелеген ТКАЕның элеккеге мөдире профессор Дурсун Йылдырымнан алдым һәм моның өчен аңа үземнең тирән рәхмәтемне белдерәм.

Хәмит Зөбәер Кошай (1897–1984), Әкъдәс Нигъмәт Курат (1903–1971), Надир Дәүләт (1944–2021) һ.б. Әгъза-корреспондентлар арасында исә Казан һәм Кырым татар зыялыларыннан Сәгадәт Чагатай-Исхакый, Абдулла Баттал Таймас, Мәхмүт Таһир, Тамурбәк Дәүләтшин, Әдигәй Кырымал, Осман Баубәк һ.б. шәхесләр бар.

Үз бинасы булмаганга, институт башта дәүләттән килгән аз гына акчага Тунис урамындагы бинага аренда түләп яши, бу акча җитми башлагач, татар хәйриячесе Әхмәт Вәли Мәңгәр (1891–1978) матди ярдәм күрсәтә. Әхмәт Тимерне Гамбург университетына эшкә чакыргач, 1975 елдан институт мөдирлегенә күренекле тюрколог профессор Шөкрю Әлчин (1912–2008) килә. Бина арендасы даими үскәнгә, институт Әнкараның Бахчелиевләр мәхәлләсендәге бер йортка күченә. Бу бакчалы йортның хуҗалары бертуган укытучы ханымнар, үзләренә квартира алып бирү шарты белән, әлеге йортны институтка бирәләр. Басылган китап-журналларны, ул елларда эшләгән Зыя Гёкальп медальонын саткан акчага ТКАЕ шулай итеп үзенең мөстәкыйль бинасына һәм хәтта кечкенә генә бер китап кибетенә ия була. Бүген дә институт ошбу адреста эшли: Bahçelievler, 69. Sokak, № 38. Институт җитәкчелеге, кулындагы матди мөмкинлекләрен туплап, яңа бина салу эшенә керешә һәм 2006 елда офислары, китапханәсе, уку залы, конференцияләр уздыру өчен 110 кеше сыйдырышлы зур салоны һ.б. мөмкинлекләре булган бер фәнни-тикшеренү үзәге төзелә.

2000 елларга кадәр институт азмы-күпме дәүләттән матди ярдәм алган булса, аннан соң бу ярдәм дә бетә, шуңа күрә үз хәлен үзе күрергә мәҗбүр булган оешма китап сатудан, бинаның бер өлешен арендага бирүдән һәм ТКАЕ әгзаларыннан кергән взнослар хисабына яши. 2006 елдан 2021 елның августына кадәр ТКАЕны Рәшид Рәхмәти Аратның укучыларыннан берсе – профессор Дурсун Йылдырым җитәкли. 1980 еллар башында Казанга килеп, Ә. Кәримуллин, И. Надировлар белән танышып-дуслашып калган Д. Йылдырым, Әбрар абыйның үтенече белән, Ш. Мәрҗанинең ике томлык «Мөстафад әл-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» әсәренең факсимиле басмасын ТКАЕ да нәшер итү мөмкинлеген таба (1992). Бу төр факсимиле китап бастыру башка булмаганга, Мәрҗани әсәре институт эшчәнлегендә бердәнбер очрак булып тарихка кереп кала.

Институт ачылган елны ук *Төрки культура* (Türk Kültürü Dergisi) исемле айлык журнал чыгара башлый һәм бу эш 2007 ел азагына кадәр туктамый. Аның дәвамы булып *«Төрки культураны өйрәнү»* (Türk Kültürü Araştırmaları) журналы оеша. Өченче журнал «*Cultura Turcica»,* инглиз, алман һәм француз телләрендә мәкаләр бастырып, тюркология өлкәсендәге яңалыкларны, табышларны гыйлем дөньясына танытуны максат итеп куйса да, озын гомерле булмый, берничә саннан соң чыгудан туктый. Финанслау бик авыр булганлыктан, *Türk Kültürü Araştırmaları* дә, кызганычка каршы, инде чыгудан туктаган.

ТКАЕның иң мөһим гамәле итеп нәшрият өлкәсендәге эшчәнлеген, А һм Б серияләрендә чыккан фәнни һәм фәнни-популяр хезмәт-

ләрне күрсәтергә кирәк. Аеруча әһәмиятле А сериясендә Төркиядән читтә яшәгән төрки халыклар хакында 150 ләп китап бастыру институтның гаять җитди казанышын дәлилли, А сериясендә нәшер ителгән китаплар арасында якташларыбыздан Абдулла Баттал Таймас, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Рәшит Рәхмәти Арат, Адилә Айда, Хәмит Зөбәер Кошай, Надир Дәүләт кебек татар галимнәренең хезмәтләре бар. Шулай ук профессор Фатма Өзкан тарафыннан әзерләнгән Габдулла Тукай әсәрләренең төрекчә тәрҗемәләре җыентыгы да татар белеме өлкәсенә кертелгән кыйммәтле өлеш булып тора. В сериясендә чыккан китаплар иллегә якын булып, Төркия төрекләренең фәнни проблемаларына кагылышлы темаларга багышланган.

Институтта басылган мөһим китаплар арасында дүрт томлы «Төрки дөнья» исемле белешмәлекне күрсәтергә кирәк. Хезмәтнең 1972 елда бер китап рәвешендә генә чыккан тәүге басмасы, 1992 елгы икенче басмасында киңәйтелә. Беренче томы – төрки халыкларның географиясе һәм тарихы, икенче томы – теле, мәдәнияте, сәнгате, өченче томы – төрек әдәбияты, дүртенче томы Төркиядән читтә яшәгән төрки халыкларның әдәбияты турында язылган материалларны үз эченә ала. Икенче томдагы тел өлкәсендә язылган мәкаләләрнең авторлары арасында, мәсәлән, Әхмәт Тимер һәм Рәшит Рәхмәти Арат исемнәре бар [Türk Dünyası El Kitabı, 1992].

Институт китапханәсендә илле меңнән артык китап тупланган. Бу китаплар бары тик төрки халыкларның мәдәнияте, теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате хакында булып, алар арасында дөньядагы төрки телдә сөйләшүче төрле халыклардан килгән китап-журналлар да саклана. Аларның бер өлешен Әхмәт Вәли Мәңгәр кемнәрдәндер сатып алып, институтка биреп калдырган булырга тиеш. Рәшит Рәхмәт Аратның шәхси әйберләре: эш өстәле, скрипкасы, тавла уенының да институтка калуы билгеле. Моннан тыш, Рәшит Рәхмәти Арат белән Хәмит Зөбәер Кошайдан калган китаплыклар да ТКАЕда саклана, бүгенгә кадәр ул мирас тасниф ителмәгән (опись ясалмаган) хәлдә. Бу китапханә һәм архивның төп «хуҗасы» булып, институт корылган еллардан башлап секретарь да булып эшләгән татар ханымы Сәйдә апа Арсланбәк санала. Кызганычка каршы, соңгы елларда Альцгеймер авыруына юлыккан Сәйдә ападан инде бу рухи байлык турында бернинди мәгълүмат та алып булмый.

Китапханәнең уку залы булса да, бүген файдаланылмый. Мәдәният министрлыгыннан ярдәм булмаганлыктан, китапханә ачык түгел. Гомумән, институт үзе дә елына бер-ике тапкыр уздырыла торган гомуми җыелышлар һәм конференцияләр вакытында гына ачыла кебек, чөнки бина ягылмый, җыештырып-карап торучы хезмәткәрләргә түләргә акча юк, җитәкчелек һәм әгъзалар, нигездә, пенсиядәге тюркологлар. Ягылмаган бинага, кышын түгел, җәен дә килеп эшләп утыру җиңел түгел. Иң кызганычы – югары катта саклана торган архив: монда төрле магнитофон язмалары, кулъязмалар, истәлекләр, шигырь дәфтәрләре, көндәлекләр булып, җитәкчелек беркемне дә кертми һәм күрсәтми,

сәбәбе – материалларның рәсми рәвештә теркәлмәве, монда эшләргә риза булырдай архивариусның юклыгы, аңа түләрлек хезмәт хакының табылмавы. Архивта төрле җирләрдән килгән, бүләк ителгән шәхси коллекция дип атарга мөмкин булган чыганаклар саклана, тик кемнән нәрсә килгәнен дә инде җитәкчелек хәтерләми. Бу язманы әзерләгән вакытта Д. Йылдырым-бәйгә архив турында тулырак мәгълүмат сорап мөрәҗәгать иткән идем, ул институт хезмәткәре Али Җандәмир белән берлектә архив саклана торган катка кергән, ягылмаган бинада коточкыч суык булганга, бары тик ике тартмадагы кәгазьләрне генә карап чыга алган. Кулына беренче эләккән язмаларның (Мәхмүт Таһирның архивыннан булса кирәк) бер шигырь дәфтәре, иске хәрефләр белән язылган кулдан каралямалар, Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» әсәрен алып карый алган. Картон тартманың тышына «Казанлы хәйрияче эшкуар Әхмәт Вәли Мәңгәрдән (Аллаһ рәхмәт әйләсен)» дип язылган булуын әйтте. Кыскасы, бу төргәк һәм тартмаларда татар халкының газиз мирасы саклануында шөбһә юк.

ТКАЕ белән бәйле тагын бер татар шәхесен искә алырга телим: ул – Себер татарларыннан чыккан шагыйрь Әсфәндияр Чынбай (Исфәндияр Ишгай) (1908–1992). Бөек Ватан сугышы чорында әсирлектә калып, «Идел-Урал» легионына кергән, төрле михнәтләр күргәннән соң, Әсфәндияр әфәнде 1949 елда Төркиягә килеп урнашкан. Тәүфикъ Әйди 1990 еллар башында аның белән күрешкән һәм үзенең китабында бу турыда телгә алган иде [Әйди, 1994, б. 35–40]. Әсфәндияр Чынбай Төркиядә өч китап бастырган, Сәйдә ханым Арсланбәкнең хәбәр итүенә караганда, үлгәнче дүртенче китабын да басмага хәзерләп бетерергә тырышкан булган, ләкин җитешә алмый калган. Гомеренең соңгы елларында аның ТКАЕда эшләве һәм үз китапларын да шул архивка калдыруы билгеле. Әсфәндияр Чынбай 1992 елның 16 июнендә Әнкарада вафат булган. Бу турыда матбугатта хәбәр бастырган Сәйдә апа Арысланбәк аны «һәрвакыт сабыр, иманлы һәм Төркиядә яшәве өчен бик бәхетле иде», дип искә ала [Арысланбәк, 1992].

Хәзерге вакытта ТКАЕ белән күренекле профессор Әхмәт Биҗан Эрҗиласун идарә итә. Күптән түгел генә институтның интернет сайты барлыкка килде: https://turkkulturu.org.tr

**Әдәбият**

*Арысланбәк С.* Әсфәндияр Чынбай // Шәһри Казан. 1992. 3 октябрь.

*Әйди Тәүфикъ.* Кардәшләр кочагында. Сәяхәтнамә // Казан утлары. 1994. № 9. Б. 3–84.

Türk Dünyası El Kitabı. İkinci Cilt. Dil, Kültür, Sanat. Ankara, İkinci Baskı. 1992.

*Мәкалә «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасының 3.19 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, Росссия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*